ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советлары эшчәнлегендә катнашуы турында" 2014 елның 19 ноябрендәге 155-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын үтәү хакында

Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советлары эшчәнлегендә катнашуы турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратникова мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратникова мәгълүматын игътибарга алырга.
2. Социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру һәм әлеге оешмаларда күрсәтелә торган хезмәттән файдаланучыларның тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләләрен хәл итүдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының керткән өлешен билгеләп үтәргә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларга агымдагы һәм алдагы бурычларын хәл итүдә ярдәм күрсәтү эшен дәвам итүне максатка ярашлы дип санарга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ · ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 4 июле
№ 2945-V ДС